ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
КАНАШСКОГО
СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ
ВЕРХНЕУСЛОНСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

Ул. Центральная, д.28, д. им. М. Вахитова,
422575

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ЮГАРЫ ОСЛАН
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫҢ
КАНАШ АВЫЛ
ҖИРЛЕГЕ БАШКАРМА
КОМИТЕТЫ

Үзәк ур., 28 нче йорт, М. Вахитов исем авылы,
422575

---

ПОСТАНОВЛЕНИЕ КАРАР

Тел.: (84379) 30-1-48, факс: (84379) 30-1-48.

05.11.2020 д. Канаш №19

Югары Ослан муниципаль районы Канаш авыл җирлегендә гражданнарның
үзара салым акчаларын җыю тәртибе турында

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003нче елның 6нчы октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль закон, «Җирле референдум турында» 2004нче елның 24нче мартында кабул ителгән 23-ЗРТ номерлы Татарстан Республикасы Законы, Югары Ослан муниципаль районы Канаш авыл җирлеге Уставы нигезендә, 2020нче елның 22нче октябреннән 1нче номерлы; 2020нче елның 23нче октябреннән 2-1нче номерлы, 2020нче елның 24нче октябреннән 4-1нче номерлы гражданнар җыеннарында кабул ителгән карарларны гамәлгә ашыру максатларында:

1. Югары Ослан муниципаль районы Канаш авыл җирлегендә гражданнарның үзара салым акчаларын җыю тәртибен расларга.

2. Әлеге карарны Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат рәсми порталында, Югары Ослан муниципаль районының рәсми сайтында һәм җирлекнең мәгълүмати стендларында урнаштырырга.

5. Әлеге карарның үтәлешен үзем контрольдә тотам.

Югары Ослан муниципаль районы
Канаш авыл җирлеге башлыгы урынбасары: Набаткина С. П.

Канаш авыл җирлеге
Башкарма комитетының
2020нче елның 5нче
ноябреннән 19нчы
номерлы карарына
1нче кушымта

Югары Ослан муниципаль районы Канаш авыл җирлегендә
үзара салым акчаларын җыю тәртибе

1. Әлеге Тәртип Югары Ослан муниципаль районының Канаш авыл җирлегендә гражданнарның үзара салым акчаларын җыю кагыйдәләрен билгели

2. Үзара салым акчаларын түләү 2021нче елның 1нче гыйнварыннан 2021нче елның 31нче мартына кадәр Югары Ослан муниципаль районы Канаш авыл җирлеге территориясендә теркәлгән 18 яше тулган, аларның халык җыенында катнашуларына һәм тавыш бирүдә катнашкан мөнәсәбәтләренә карамастан, башкарыла.

3. Түбәндәге категория гражданнар үзара салым акчаларын түләүдән азат ителә:

а) Бөек Ватан сугышы инвалидлары;

б) Бөек Ватан сугышында катнашучылар.

4. Аерым категория гражданнар өчен түләү күләме гражданнар җыены турында карарда билгеләнгән сумманың 50 процентын тәшкил итә

а) 1нче төркем инвалидлар,

б) күп балалы гаиләләр,

в) көндезге уку йортлары студентлары,

г) Бөек Ватан сугышы ветераннары,

д) балачактан инвалидлар

5. Бер тапкыр түләү турында хәбәр итү (хәбәрнамә) бланкы имза яки почта элемтәсе аша юллау юлы белән гражданнарга җиткерелә.

Хәбәрнамәдә (хәбәр итү) гражданнарга үзара салым акчаларын күчерүнең түләү реквизитлары, тулы яки киметелгән күләмдә бер тапкыр түләү суммасы, аны түләү срогы булырга тиеш.

6. Гражданнарның үзара салымыннан алынган акча Югары Ослан муниципаль районы Канаш авыл җирлеге Башкарма комитетының шәхси счетына керә

7. Гражданнар тарафыннан түләүләр физик затлар йөкләмәсе буенча исәп-хисапларны гамәлгә ашыру хокукына ия булган оешмалар аша почта күчерүен (исәп-хисап оешмалары) тормышка ашыруга яки Татарстан Республикасы дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр https://uslugi.tatarstan.ru/ порталы аша башкарыла.

8. Касса ордеры, чек-ордер квитанциясе, түләү фактын раслаучы башка документлар түләү фактын раслый.

9. Билгеләнгән вакытка кертелмәгән үзара салым акчалары законнарда билгеләнгән тәртиптә түләттерелә.